

«Узган елнын ноябреннән абыйлар белән апалар, салкын һава торышына һәм бозлавыкка карамастан, дәресләрне калдырмаска тырыштылар. Уку вакытында алар Коръәннән кыска сүрәләрне ятладылар, намаз укырга ойрәнделәр, ислам нигезләре һәм Ислам дине турында күп нәрсәләр белделәр», - дип яза Раиль хазрәт МУСИН, Дубенка белән Чамзинка, Ардатов һәм тагы 3 район моселманнары имам-мухтасибы үзенен ВКонтакте битендә.

Безнен чарада Чамзинка муниципаль районы башлыгы Руслан Альфред улы Батеряков, Комсомольск поселогы башлыгы Илдар Илдус улы Жәлилов, яна сайланган Мордовия мофтие Абдулмалик хәзрәт Асаинов, хәзрәтләр һәм безнен активистлар катнашты.
Чамзинка районы башлыгы Руслан Альфредович Батеряков Якшәмбе мәктәбен тәмамлаучыларны котлады, Чамзинка районы моселманнарын Чамзинка татар зиратында яткан ата-бабаларыбыз алдындагы бурычыбызны онытмаска ондәде, гражданнарнын үзара салым салу (самообложение граждан) программасында катнашырга һәм бу акчаларны зират территориясен яна коймa белән коймаларга кулланырга тәкъдим итте.
Үзенен чыгышында мофти Абдулмалик хәзрәт барлык шәкертләрне бәйрәмнәре белән котлады, белемнен файдасы турында сойләде һәм барысына да ирешкәннәрендә тукталмаска һәм алга таба да дини белемнәр алырга чакырды. Чыгышынын азагында Абдулмалик хәзрәт укучы хатын-кызларга чәчәк бәйләмнәре бүләк итте, шунын белән безнен чараны бизәде һәм хатын-кызлар күнелендә күп хисләр уятты.
Шәкертләремнән мина карата бик күп рәхмәт сүзләре янгырады, ә минем очен ин күнелле сюрприз - алар мина биргән бүләк иде. Чара ахырында барыбызны да бәйрәм остәле котте; бу остәл безнен укучылар тарафыннан әзерләнде.
Мин ин беренче чиратта Аллаһы Тәгаләгә безгә файдалы белемнәр алуда һәм әлбәттә минем шәкертләремнен Ислам һәм татар халкынын гореф-гадәтләре турында белем алуда активлыгы һәм тырышлыгы очен рәхмәт белдерәм.

**Раиль МУСИН**